Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Биектау авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

20 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Биектау торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Биектау торак пунктында су белән тәэмин итү системасы эчтәлеге (тирән насослар сатып алу);
- Биектау торак пунктында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Биектау т. п. да урамнарның юл өлешен кышкы чорда кардан чистарту (урамнарны чистарту);
- Биектау т. п. да К. Насыйри, Г.Ибрагимов, Х.Сафиуллин, Вахитов, Чапаев урамнарында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Биектау т. п. Ленин урамында урам юлларын ремонтлау;
- Биектау торак пунктында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- Биектау т.п. да су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү;
- Сабанчи, Р.Хаким урам юлларындагы чокырларны ремонтлау.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 522 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 280 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 280 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге составына керүче Биектау авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныrга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Биектау торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Биектау торак пунктында су белән тәэмин итү системасы эчтәлеге (тирән насослар сатып алу);
- Биектау торак пунктында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Биектау т. п. да урамнарның юл өлешен кышкы чорда кардан чистарту (урамнарны чистарту);
- Биектау т. п. да К. Насыйри, Г.Ибрагимов, Х.Сафиуллин, Вахитов, Чапаев урамнарында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Биектау т. п. Ленин урамында урам юлларын ремонтлау;
- Биектау торак пунктында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- Яңавыл т.п. да су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү;
- Сабанчи, Р.Хаким урам юлларындагы чокырларны ремонтлау.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гилазиева А.Р.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Гилазиева А.Р.